*Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы “Наласа гомуми үсеш бирү төрендәге “Балачак” балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе*



# Чишмә башы

*Май, 2026 ел*






***Ата-аналар һәм балалар өчен кызыклы мәгълүматлар***

## Май аена сынамышлар

***Май суык булса – икмәк уңа.***
***Яңгырлар еш явып, томан еш төшсә – уңышлы елга.***
***Май яңгырлы булса, июнь коры килә яки киресенчә.***
***Майда боз яуса, җәен дә явачак.***
***1 майда җылы булса, май ахыры салкынча булыр.***
***2 майда каен яфрак ярса, җәй коры килер.***
***3 майда ике яки өч катлы салават күпере чыкса, берничә көннән көчле яңгыр булыр.***
***4 майда шомырт чәчәк атса, җәй җылы килер.***
***5 майда төнлә салкынайтса, 40 көн буена иртәләр салкын булыр.***
***6 майда көн суык булып, бер атнада тагын кабатланса, җылы көз көтегез.***
***7 майдан соң, гадәттә, 12 суык була.***
***8 майда яңгыр яуса, арыш уңа.***
***9 майда көндез җил көчле булып, кичкә тынса, тотрыклы аяз көннәргә ишарә.***
***10 майда кояш чыкканда, көн аяз булса – җәй җилле булыр.***
***11 майда таң атканда йолдызлар җемелдәшсә, якын арада яңгыр көтелә. Күбәләкләр өйгә яки сарайга кереп качса, көн суыта.***
***12 майда көчле җил — көчле яңгыр алып килә.***
***13 майның җылы киче һәм йолдызлы төне – мул уңыш билгесе.***
***14 майда көн бозыла икән, кыш салкын булыр.***
***15 май төнендә сандугач төне буе сайрап чыга икән, кояшлы көн көтегез.***
***16 майда шомырт чәчәк атса – салкынайта, шомырт чәчәге күп булса, яңгырлы җәй килә.***
***17 майда чыпчыклар төркемләп очса, көчле җил булыр.***
***18 майда каз суда коенса, көннәр җылыта.***
***19 майда чык күп төшеп, көн кояшлы булса, кыяр уңышы мулдан булыр.***
***20 майда кичке салават күпере – аяз, иртәнгесе яңгырлы көнгә. Төнлә су өстенә томан ятып, иртән юкка чыкса, аяз көннәргә ишарә.***
***21 майда яңгыр яуса, гөмбәле ел килә.***
***22 майда яңгыр яуса, бодай һәм арыш уңар.***
***23 майда яңгыр яуса, җәй яңгырлы килер. Тузганак чәчәкләре төштән соң 2дә, 3тә ябылса, яңгыр явар.***
***24 майда яңгыр сибәләсә, яңгырлы җәй юрыйлар.***
***25 майда төркем-төркем болытлар бер якка таба гына акса, коры көннәр килә.***
***26 майда карлыгачлар түбән очса, яңгыр көтегез.***
***27 майда яр карлыгачлары күренсә, җылы көннәр килә.***
***28 майда көн кызу булса, җәй дә җылы булыр.***
***29 майда суда төнбоек яфраклары күрсәгез, язгы суыклар бетте дигән сүз.***
***30 майда көн нинди булса, җәй дә шундый.***
***31 майда черкиләр болыт булып җыелса, матур һава торышына. Бал кортлары шомырт һәм миләш чәчәгенә кунса, июньнең беренче көне матур булыр.***



## 7 атна – #ЭКО ЯЗ БӘЙГЕСЕ *« Безнең Геройлар янәшәдә яши »*

Яз житү белән һәйкәлләрне карау һәм тәртипкә китерү - һәрберебезнең бурычы. Чиста һәйкәл – үткәнгә, тарихка рәхмәт белдерү, ансыз киләчәк юк. Безнең изге бурычыбыз – яшәүче ветераннарны гына түгел, инде безнең арада булмаганнарны да кайгырту, хәтерне саклау һәм Бөек Җиңү тарихын киләчәк буыннарга тапшыру. Һәйкәлне төзекләндерү – сугышны үткән буын алдында, аларның батырлыгы һәм нык-лыгы алдында хөрмәт белдерү. Бу – безнең эшләребезнең кечкенә генә бер өлеше, авылыбызның киләчәген кайгырту, яшь буынның бабаларыбыз хәтерен хөрмәт итүе өчен. Безнең төп бурычыбыз – бу хәтерне еллар буена саклап калу. Без балалар белән һәйкәл тирәсендәге территорияне тәртипкә китердек, чистарттык. Ба-рысы да күтәренке күңел белән эшләде. Кемдер яфрак җыйды, кемдер аны өемнәргә туплады, кемдер капчыкларга салды. Эшләренең нәтиҗәсен күрү, балалар өчен бик күңелле, горурлык булды, һәркем бу эшкә үз өлешен, җылысын кертте. Мондый чаралар яшь буынга ватанпәрвәрлек хисләрен тәрбияли. Үз тор-мышлары бәясе белән, безгә тынычлык һәм ирек бүләк иткән ветераннарыбызны хөрмәтлибез, аларга чиксез рәхмәтлебез.







**« Хәтердә сез, һәлак булганнар! »**
Рәхмәт сезгә исән калганнар!
Ветераннар, ветераннар,
Сезгә хөрмәт, ихтирамнар.
Сез булганга матур булып,
Алсу булып ата таңнар.
Сугышта булып арыслан
Ватанга җиңү яулаган,
Тыныч хезмәттә дан алган
Һәр ветеран – чын каһарман.



9 май - Җиңү көне якынлашканда без балалар белән Бөек Ватан сугышы ветераны Насыйбуллин Илдус бабай белән очрашуга бардык. Тормышта төрле хәлләрне күргән, ләкин сынмаган, сыгылмаган кыю ир кеше ул.Илдус бабайга матур теләкләр теләдек, бәйрәм белән котлап үз кулларыбыз белән ясалган кот-лау открыткасы, күчтәнәчләр тапшырдык.Шулай ук аның бакчасындагы, капка төбендәге, ишек алдындагы чүпләрне җыеп, себереп, тырмалап алдык.Илдус бабай үз чиратында безгә рәхмәт укып, тәм-томнар белән сыйлады. Без ветераннарыбыз белән чиксез горурланабыз. Аларның батырлыгы, түземлеге, кыюлыгы ал-дында баш иябез.


***7 атна – #ЭКО ЯЗ БӘЙГЕСЕ «Без аерым җыю өчен»***

Балалар бакчасының зурлар төркемендә тәрбияләнүчеләре «Экояз-2026» республика конкурсының « Без аерым җыю өчен » дип аталган атнаны башлап җибәрделәр. Балалар эти - әниләре белән бергә актив катнаштылар. Беренчеләрдән булып макулатура алып килүче төркем. 69,741 кг макулатура алып килеп тапшырдылар.Мәктәпкә әзерлек төркеме тәрбияләнүчеләре 50,591 кг макулатура җыйдылар һәм эшкәртүгә тапшырдылар. Кечкенәләр төркемендә тәрбияләнүчеләр « Экояз 2026» республика конкурсының «Без аерым җыю өчен » акциясендә эти- әниләре белән бергә актив катнаштылар. Конкурста катнашып,һәр тәрбияләнүче үзен планетаның бөек коткаручысы итеп хис итте. Алар 103 .40 кг макулатура җыйдылар һәм эшкәртүгә тапшырдылар. Акциядә катнашучыларга зур рәхмәтебезне белдерәбез!





***8 атна – #ЭКО ЯЗ БӘЙГЕСЕ «Чиста су»***



***(яр буе территорияләрен, елгаларны, чишмәләрне һәм күлләрне чистарту)***

«ЭКОЯЗ2026»ның «Чиста су» (яр буе территорияләрен, елгаларны, чишмәләрне һәм күлләрне чистарту) дип аталган ахыргы сигезенче атнасы башланып китте. Безнең балалар бакчасында тәрбияләнүче кечкенәләр төркеменнән : Төхфәтуллин Йосыф,Ризванов Рамазан,Галиуллин Әмирхан, Насибуллина Эмилия, Закиров Аяз;өлкән төркем балалары: Гафуров Риналь,Сибагатуллин Рамазан, Мөхәммәтҗанова Зәлия ,Төхбәтуллина Ясминә;мәктәпкә әзерлек төркемендә тәрбияләнүче: Хәлиуллин Райнур, Рәхимов Ризат,Төхфәтуллина Сәйдә, Юнысов Әмир катнашты.

Тәрбияләнүчеләребез сулык ярларын чүп-чардан чистартуга игътибарларын юнәлттеләр. Чиста ярлар -сәламәт сулыклар, димәк, саф һава да, хайваннар да, барыбыз өчен дә шатлык.Яр буе территорияләрен чистарту - һәркемнең киләчәккә керткән өлеше!

Чиста елгалар-чиста тормыш! Елгалар - безнең табигый хәзинәләребез.Безнең елгаларның чисталыгына күп нәрсә бәйле: эчә торган суның сыйфатыннан алып әйләнә-тирә мохитнең торышына һәм халыкның сәламәтлегенә кадәр.Шуңа күрә су артерияләребезнең ярларын калдыклардан чистартып, табигатьне чиста һәм сәламәт итеп саклау мөһим.  Әйдәгез табигатьне бергә саклыйк!








## «Бөек Җиңү көне белән!»







8 май көнне, БөекҖиңүнең 81 еллыгы алдыннан Наласа «Балачак» балалар бакчасы, Наласа урта гомуми белем бирү мәктәбе, мәдәният йорты белән берлектә Җиңүнең 81 еллыгына багышланган чара узды. Чара программасына Җиңү бәйрәме, тынычлык, Ватанны саклаучыларның үлемсез батырлыгы турында «Билгесез солдат» һәйкәленә чәчәкләр куелды, һәлак булучылар бер минут тынлык белән искә алынды. Без фронтта, тылда көтелгән Җиңүне якынайткан бабайларыбыз, әбиләребез батырлыкларын хәтерлибез һәм хөрмәт итәбез. Аларның фидакарьлеге Ватанга мәхәббәт һәм патриотизм үрнәге булсын, ә җиңүче буынга рәхмәтлелеге безнең йөрәкләребездә һәрвакыт яшәсен!

## «Җиңү тәрәзәләре»
















# «Балалар бакчасында ата-аналар жыелышы»

Балалар бакчасында ата-аналар жыелышы булып узды.


Тәрбияче Гафурова Рафия уку елын йомгаклау җыелышында зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының уку елы башында куелган бурыч,максатларның үтәлеше турында сөйләде. Тәрбияләнүчеләрнең программаны үзләштерүләрен гади һәм махсус оештырылган эшчәнлектә активлыкларын күзәтү барышында I нче яртыеллык һәм II яртыеллыкта педагогик диагностика үтәлешенең нәтиҗәләре белән таныштырды. Йомгаклау өлешендә әти- әниләргә ел буе балалар бакчасы белән бердәм,дус булып , барлык эшләрдә актив катнашканнары өчен чиксез рәхмәтен җиткерде.

Тәрбияче Хөсәенова Римма Нәзгать кызы мәктәпкәчә белем бирүнең Федераль белем бирү программасы буенча уку елы ахырына 3-4, 4-5 яшьлек балаларның белем бирү өлкәләре буенча нинди белем һәм күнекмәләргә ия булырга тиеш икәне турында сөйләде. Программаның максаты -баланың яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, җәмгыятьнең рухи-әхлакый кыйммәтләре нигезендә, аны төрле яклап үстерү.

Көн тәртибенең өченче өлешендә сүз тәрбиячебез Галиуллина Алинә Фидаэль кызына бирелде. Ул 2025-2026 нчы елның уку елына балалар бакчасының җәйге сәламәтләндерү чорына эш планы белән таныштырды.Чыгышының икенче өлешендә балалар травматизмының типик очраклары, аны кисәтү чаралары турында сөйләде.







## *Безнең уңышлар*







Г.Тукайның тууына 140 ел тулуга багышланган « Тукай әкиятләре дөньясында» районкүләм рәсем бәйгесендә катнашып,безнең балалар бакчасында тәрбияләнүче Юнысов Әмир Рәмис улы,Төхфәтуллин Йосыф Фәннур улы 3 дәрәҗәдәге Дипломнар белән бүләкләнделәр. Киләчәктә дә унышлар телибез .

Арча шәһәренең 11 нче номерлы«Күбәләк»балалар бакчасында районкүләм «Яшь полиглот» бәйгесе булып үтте.
Полиглот – күп телләр белүче дигәнне аңлата. Кеше никадәр күбрәк тел белсә, шулкадәр күбрәк белем алырлык сәләткә ирешә ала, рухи яктан бай була дигән гыйбарә бар. Бакчабыздан катнашучы Мөхетдинова Әнисә өч телдә үзенең осталыгын күрсәтеп, 1 урынга лаек булды. Әфәрин!Әнисәне чын күңелебездән котлыйбыз, алдагы бәйгеләрдә уңышлар телибез.

Воспитанники нашего детского сада Халиуллин Районур и Тухбатуллина Саида приняли участие в Фестивале чемпионов Всероссийского физкультурно-спортивного комплекса «Готов к труду и обороне» (ГТО) в Республике Татарстан «ИГРЫ ГТО» среди дошколят Арского муниципального района, заняли II место.Молодцы, поздравляем.Желаем дальнейших успехов .

# ***«Сау бул бакча!»***

***Май азагы һәрвакыт чыгарылыш кичәләре белән билгеләп үтелә. Балалар бакчасында чыгарылыш кичәсе-моңсу да, шатлыклы да: балалар бакча белән саубуллашалар, алда аларны «мәктәп» дип аталган яңа тормыш көтә. Зал бизәлгән, әти-әниләр, кунаклар чакырылган, барысы да дулкынлана. Һәм менә бәйрәмчә киенгән балалар керә – бәйрәм башлана.***

***Бәйрәм «Сау бул бакча» дип атала. Төрле әкият геройлары булып киенеп ,бакча хезмәткәрләре балаларга матур бәйрәм оештырдылар. Тамаша вакытында балалар үзләренең бакчада өйрәнгәннәрен күрсәттеләр - җырладылар, биеделәр, матур итеп шигырьләр сөйләделәр, табышмакларга җавап бирделәр, математик бурычларны чиштеләр. Балалар бакчасы мөдире Гафурова Эльмира Рашат кызы чыгарылыш төркем балаларына мәктәп тормышы дәвамында уңышлар, зур үрләргә ирешүләрен теләде һәм беренче документ – балалар бакчасын тәмамлау турында диплом тапшырды. Без дә чыгарылыш балаларын чын күңелдән котлыйбыз һәм киләчәктә укуларында уңышлар теләп калабыз.***
























***Газетаны оештыручы һәм баш мөхәррир:*** *Галиуллина А.Ф..,Галиуллина А.Ф.*
***Редколлегия әгъзалары****: Гафурова Р.А., Хөсәенова Р.Н., Гафурова Э.Р.*
*Адрес: 422018 ТР, Арча районы, Наласа авылы, Үзәк урам, 76 йорт*